**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Пычак авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«18» декабрь, 2023 ел № 29

Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025 һәм 2026 нчы елларның план чорына бюджеты турында

Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджет проектын карап чыгып, Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

**1 статья**

1. 2024 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2148300,00 сум;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2148300,00 сум.

3) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профицит) 0 сум күләмендә.

2. 2025 елга һәм 2026 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2025 елга 2212900,00 сум һәм 2026 елга 2271200,00 сум күләмендә;

2) 2025 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 2198612,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 14288,00 сум һәм 2026 елга 2241785,00сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 29415,00 сум;

3) 2025 елга авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профициты) 0 сум, 2026 елга 0 сум күләмендә.

3. Авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2024 елга әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2025 елга һәм 2026 елга әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

1. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

2. 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

2. 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2027 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Авыл җирлеге бюджетында 2024 елга авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына әлеге Карарга 4 нче һәм 5 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

**5 статья**

Авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2024 елга әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2025 елга әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2026 елга әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә.

**6 статья**

Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге бюджетында Кукмара муниципаль районы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертларны 2024 нче елга 1591,8 мең сум, 2025 нче елга 1641,4 мең сум, 2026 нчы елга 1682,9 мең сум күләмендә исәпкә алырга, шул исәптән:

- муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр 2024 елга 1484,7 мең сум, 2025 елга 1523,5 мең сум, 2026 елга 1553,7 мең сум күләмендә.

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына 2024 елга 107,1 мең сум, 2025 елга 117,9 мең сум, 2026 елга 129,2 мең сум күләмендә субвенцияләр;

**7 статья**

Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге башкарма комитеты 2024 һәм 2025 – 2026 елларда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре

хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

**8 статья**

Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге бюджетыннан авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен файдаланылмаган, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2023 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә акча калдыклары, авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2024 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**10 статья**

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11 статья**

Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына элү юлы белән халыкка игълан итәргә.

Кукмара муниципаль районы
Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш.Нафиков